Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Боерган авылы

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«22» ноябрь, 2021 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Боерган авыл җирлеге Боерган авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2022 елда яшәү урыны буенча Боерган авыл җирлеге Боерган авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) Боерган авылы Новая урамын төзекләндерү;

2) Боерган авылы Тойгузино, Мирная урамнарында суүткәргеч челтәрен(330м) төзекләндерү;

3) Янгын сүндерү машинасы гаражының түбәсен төзекләндерү.

2. Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Боерган авылы гражданнар җыены карарын авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Боерган авылы гражданнар җыены карарын Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Боерган авыл җирлеге Башлыгы Г.Г.Минакова